**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**УЗЯКСКИЙ СЕЛЬСКИЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ**
**КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Татарстан ул., д. 7, п. Узяк, 422092
тел. (факс): (84360) 5-22-17,
E-mail: Uzk.Tul@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ҮЗӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Татарстан ур., 7 нчы йорт, Үзәк бистәсе, 422092
тел. (факс): (84360) 5-22-17,
E-mail: Uzk.Tul@tatar.ru

ОКПО 93053615 ОГРН 1061675010165 ИНН/КПП 1619004370/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«03» ноября 2022 г.**

**№ 16**

**Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 22 июндәге 14 номерлы «Адресация объектына адрес бирү, андый адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 26 июлендәге 1332 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 22 июндәге 14 номерлы «Адресация объектына адрес бирү, андый адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Адресация объектына адрес бирү, андый адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына:

- 2.20 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Кагыйдәләрнең 2.15 пунктындагы"б", "д", "з" һәм "и" пунктчаларында күрсәтелгән документлар башкарма хакимиятнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында булган белешмәләрне бирүгә вәкаләтле федераль органы яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә "Роскадастр" гавами-хокукый компаниясе турында" Федераль закон нигезендә вәкаләтле орган соравы буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә төзелгән гавами-хокукый компания тарафыннан тәкъдим ителә.»;

- 3.3 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәне формат - логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең һәрбер электрон форма гарызнамәсен тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең электрон рәвештә тутырылган кырының корректлы булмавы ачыкланса, мөрәҗәгать итүчегә турыдан-туры гарызнамәнең электрон формасында ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр ителә.»

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Үзәк авыл җирлеге башлыгы В.Н.Котников